УДК 821.512.145

***Г.И. Каюмова***

# ҺӘРНӘРСӘДӘН МАТУРЛЫК ЭЗЛӘҮЧЕ ШАГЫЙРЬ

***(Гамил Афзалның тууына 105 ел тулу уңаеннан)***

Творчество народного поэта Республики Татарстан Гамиля Афзала, оказавшее значительное влияние на общественно-культурную жизнь татарского народа, покорило широкую общественность искренностью, яркостью, смелостью, духовно-нравственной ценностью и воспитательным потенциалом. Поэт был погружен в историческое прошлое своего народа и эпоху, в которую жил, сопереживал современникам, хорошо понимал общественные перемены и положение в стране, что нашло отражение в его поэтических произведениях. Лирика Г. Афзала многогранна как в жанровом, так и в идейно-тематическом аспектах, она характеризуется обращением к народным образам и мотивам, философичностью, также поэту присуще юмористическое восприятие мира.

Данная статья призвана обозначить ключевые векторы поэзии Г. Афзала. На материале ряда произведений автор исследования выявляет сквозные проблемы, освещенные в творчестве поэта и являющиеся неотъемлемой частью духовных ценностей татарского народа (отношение к родной земле, родному языку, природе; взаимоотношения с близкими, между людьми; судьба нации, национально-нравственное воспитание, общественные пороки, изъяны характера и т. д.).

**Ключевые слова:** Гамиль Афзал, поэт, поэзия, лирика, юмор, сатира, красота, воспитание

The poetry of Gamil Afzal, the national poet of the Republic of Tatarstan, is a work that has captivated the general public with its sincerity, brightness, courage, spiritual and moral value and educational significance, which has had a significant impact on social and public life. The writer is well aware of the historical past of the Tatar people, the era in which he lived, his people, their interests, social changes, and the situation in the country, which is reflected in his poetic works. His folk lyrics inspire, philosophical poems encourage reflection and teach, humorous poems have a healing effect, and satire has a purifying and educational power.

This article is intended to recall the truly unique work of G. Afzal, in particular his poetry, to reveal its significance in the life of the people, using the example of his individual poems to highlight current problems of all times (attitude to his native land, native language, nature; relationships with loved ones, between people; the fate of the nation, national and moral education, social vices, character flaws, etc.). Thus, the purpose of this article is to comprehend the poet's original legacy and convey its deep meaning to a wide audience.

**Keywords:** Gamil Afzal, poet, poetry, lyrics, humor, satire, beauty, education

Татарстан Республикасының халык шагыйре, «торгынлык чорының иң зур корбаннарыннан берсе» [3: 151] Г. Афзал (1921–2003) – лирик, юмористик-сатирик шигырьләр, кыска хикәяләр, юморескалар

һәм этюдлар авторы. Аның татар, рус, башкорт телләрендә нәшер ителгән өч дистәдән артык китабы дөнья күрә.

Әдип кечкенәдән Г. Кандалый, Г. Тукай, Ш. Бабич, Һ. Такташ шигырьләрен укып рухланып үсә, алар тәэсирендә үзе дә каләм тибрәтә башлый. Шагыйрьнең иҗат хәзинәсе халыкчан булуы, сыгылмалы бай теле белән аерылып тора һәм бик күпләрне үзенә җәлеп итә. Аның әсәрләрен яратып укыйлар, анализлыйлар, шома, йөгерек, җор теленә сокланалар; галимнәр һәм язучылар (М. Әхмәтҗан, С. Баттал, Ф. Бәйрәмова, Т. Галиуллин, Р. Гаташ, И. Гилаева, Г. Гыйльманов, Д. Заһидуллина, Зөлфәт, Л. Кәшфи, М. Мирза, Р. Мостафин, Ф. Садриев, Н. Хисамов, Л. Шәех, Н. Юзиев, М. Юныс, А. Яхин һ. б.) төрле яклап тикшерәләр һәм фикерләре белән уртаклашалар. И. Гилаева, Г. Афзал лирикасын һәм сатирасын тирәнтен өйрәнеп, кандидатлык диссертациясе яза (2004). Шулай да соңгы елларда әдип иҗатын яктырткан мәкаләләр юк диярлек. Язучының юбилее уңаеннан, гуманизм белән сугарылган үзенчәлекле шигъриятен искә төшереп, аерым әсәрләренә тукталып, әлеге иҗатның тәрбияви әһәмиятен билгеләп үтү максатка ярашлы булыр дип уйлыйбыз.

Г. Афзалны «пәйгамбәргә тиң шагыйрь» [16], «зирәк аксакал», «дистәләгән яшь язучыларны чын иҗатка тәрбияләгән остаз, җәмгыятебезнең әхлакый сафлыгы сагында торучы уяу солдат, милләтебезнең йөзек кашы» [9], «гамь һәм моң илчесе» [6], «шагыйрь нечкә тоемлы күңелгә, чичәннәрнекедәй телгә ия» [14] дип, зурлап искә алалар. Әдәбият галиме Н. Юзиев фикеренчә, «чичәнлек рухы – шагыйрьнең көчле ягы, аның талантына үзгә бер матурлык бирүче хасият» [5: 65]. Сатирик язучы Ф. Баттал, әдипнең алдан күрүчәнлек сәләтенә басым ясый: «әүлия да, философ та ул.., көтүчедән министрга чаклы теләсә кемнең күзенә туры карап сөйләште, патшалар тәхете өстеннән торып фикер йөртте, тормышның хөкемдары да, намусы һәм хакиме дә, Хуҗа Насретдины да булды» [3: 150]. «Туры сүзле, үз принципларыннан мәңге чигенмәс, үтә дә тыйнак яшәүче, гаять тирән, төпле фикерләүче һәм балаларча беркатлы бу кешене инде егерме елга якын бергә иҗади аралашу чорында мин чынчынлап яратып өлгердем. Мин аңа сокланам һәм аңарга охшарга тырышам», – дип яза язучы Ф. Садриев [13: 139]. «Аны беркем белән дә чагыштырып торырга кирәкми. Гамил Афзал ул, ни дисәгез дә, бер генә инде!» – ди язучы З. Дәүләтов [9: 171].

Кешелекле, мәрхәмәтле, чын кеше була белгән, «халыктан алган шигъри таланты белән шул халыкка хезмәт итү»не [5: 77] максат иткән кеше генә шундый ихтирамга лаек. Г. Афзал нәкъ менә шундый олпат шәхесләрнең берсе була. Шигъриятенең күпкырлылыгын, мәгълүмати киңлеген исәпкә алсак, аның турында энциклопедик белемле шагыйрь дип әйтергә мөмкин. Бу уңайдан Башкортстанның халык шагыйре Н. Нәҗми сүзләре игътибарга лаек: «Шагыйрьдә шагыйрьлек белән галимлек бербөтен булып яшәргә тиеш. Чын шагыйрь – үзе галим, ул гомер буе ачыш белән яши» [5: 73].

Шигърияткә әдипнең сикәлтәле, михнәт-газап тулы урау юллар аша килүе һәркемгә мәгълүм. Бу уңайдан язучы, публицист М. Юныс сүзләрен искә алу урынлы булыр: «Гамилнең тәрҗемәи хәле татар язмышына охшашлы» [18]. Ул, чор сулышын нечкә тоеп, заман белән бергә атлый, халык тормышы белән яши, аның белән кайгыра һәм сөенә, шигырьләрендә матурлыкны данлый, әдәп-әхлак, милли-рухи тәрбия мәсьәләләрен, милләт язмышы белән бәйле проблемаларны калку яктырта, һәртөрле ямьсезлекне, ягъни төрле социаль-иҗтимагый җитешсезлекләрне, кеше холкына хас кимчелекләрне, затсыз күренешләрне фашлый; әдип авыл кешесенең психологиясен яхшы тоя, күңел төбендәгесен бар нечкәлекләре белән ачып бирә. Җыеп әйткәндә, аның тезмә әсәрләрендә «милли космосыбыз шулкадәр төгәл, мул чагыла» [18].

1937 елда Г. Афзалның Баку шәһәрендә чыга торган «Баку эшчесе» газетасында «Магнитогорск» исемле беренче шигыре басыла. 1955 елда «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында шагыйрьнең 9 шигыре нәшер ителә. Халыкчан юмор белән сугарылган, гаҗәеп заманча яңгырашлы бу шигырьләр әдәбият сөючеләр һәм киң җәмәгатьчелек тарафыннан җылы кабул ителә. Аннары бер-бер артлы шигъри җыентыклары дөнья күрә. Г. Афзал 1977 елда «Айлы кичләр» шигъри җыентыгы һәм «Борылам да карыйм» циклына кергән шигырьләре өчен Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

Г. Афзал 1950 еллар ахыры – 1960 елларда башлыча юмор-сатира жанрында актив иҗат итә, 1970 еллардан башлап иҗатында фәлсәфи лирика өстенлек ала. Тулаем алганда, автор иҗатында лирика белән юмор-сатира, гадәттә, бергә үрелеп бара: лирик геройның күңел халәтен, рухи дөньясын гәүдәләндерүче лириканы лирик кичерешләр белән үрелгән юмор бизәп тора. Әдәбият галиме Н. Хисамов фикеренчә, «Гамил Афзалның сатирасын лирик героеның тормышны раслаучан фәлсәфәсеннән аерып карау мөмкин түгел. Шагыйрь һәр ике жанрда үзен бердәй көч белән танытты» [15: 143].

Г. Афзалны милләт язмышы, туган тел, тәрбия мәсьәләләре, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр борчый. Шагыйрь тормышны, кешеләрне ярата. Шигырьләрендә дә кешене олылауга, аны данлауга зур урын бирелә, һәркемнең бәхеткә лаек булуы ассызыклана, әдип кешенең кадерен белергә өнди. Шул уңайдан түбәндәге юлларга күз салыйк: *Кеше – даһи тереклекнең терәге ул, / Мәңгелекнең иң кадерле бүләге ул. / Табигатьнең миллион еллар сайлап-сайлап / Чарлый торган нәфис сәнгать үрнәге ул... Ике кат яшәмәс бераү дә, / Чәчәкләр бирегез кешегә!* [1: 16] («Чәчәкләр бирегез!»). «Йөз кабат» шигырендә: *Йөз кабат сөенәм, хушланам, / Йөз кабат сокланам кешегә!* [1: 11] – ди. Пакь күңелле кеше генә башкалар бәхетенә сөенә, кешеләрне ярата ала. Шагыйрьнең «Үзем турында» шигыренә күз төшерсәң, моның, һичшиксез, шулай булуына инанасың: биредә авторның, көчле авыруына карамастан, башкалар бәхете өчен чын

күңелдән сөенә белүче чиста күңелле һәм киләчәктә барысы да яхшы буласына ышанучы оптимист рухлы кеше икәнлеге ачыклана: *Бәхет балкыр заман, / Ә мин ятып язам... / Күпме сагыш килде өелеп! / Үзем сүнеп ятам, / Үзем көлеп ятам, / Кеше бәхете өчен сөенеп* [1: 7]. Кешенең юктан да күңеле була, кешеләр бер-берсенә мәрхәмәтле булып, бер-берсен хөрмәтләп, бер-берсенең уңышларына сөенеп һәм сөендереп яшәсен иде дигән теләктә кала: *Күңелләр сайраша, кешеләр җырласа, / Кешеләр кешене зурласа. / Кешенең йөрәген уй баса, моң баса, / Кешегә ихтирам булмаса* [1: 116].

Г. Афзалның шигырьләрендә туган илен, туган телен яратуы, газиз туган җирен өзелеп сагынуы аңлашыла. Шул юлларны укыганда ирексездән халкыбызның туган ил, туган җиргә багышланган, шушы изге төшенчәләрнең бернәрсәгә дә алыштыргысыз зур хәзинә булуына басым ясалган күңел җәүһәрләре – мәкаль-әйтемнәре («Алтын-көмеш яуган җирдән туган-үскән ил артык», «Асыл кеше алтын дип үлмәс, халкым дип үләр», «Дустыннан аерылган җиде ел елар, иленнән аерылган гомер буе елар», «Туган-үскән җирдән дә матур җир булмас») искә төшә. Мәсәлән, *Нинди ил бар, нинди җир бар / Туган-үскән җиргә тиң?!* [1: 12] («Дөнья матур, дөнья киң!»); *Кайда йөрсәм дә, йөрәктә / Татарстан таңнары... / Сагындырып искә төшә / Татарстан таңнары* [1: 13] («Татарстан таңнары»). «Авылга кайту», «Шәрип урманы», «Туган җиреңнән китмә», «Авыл мәктәбе», «Ностальгия» шигырьләре туган-үскән җирне өзелеп ярату һәм сагыну хисе белән сугарылган. Әйтик, «Ностальгия» шигырендә лирик геройның туган ягын сагыну хисе шулкадәр көчле ки, хәтта зиратына ятып елыйсы килә аның. «Матурлык эзлим» шигырендә лирик герой матурлыкны, халык мәкальләрендәге кебек, бары туган ягында гына таба: *Юк, кирәкми миңа мәрмәр сарай, / Төкермим дә алтын-көмешкә; / Миңа ипи белән катык ярый, / Миңа рәхәт шушы килеш тә* [1: 13]. Автор гомерне заяга уздырмаска, чәчәк гомере кебек кыска гомерләрнең кадерен белеп калырга чакыра («Чәчәк гомерләре»). «Ташландык авыл» шигырендә әдипнең авылларның чүп базы булып ятуына, эчкечелекнең, явызлыкның чәчәк атуына, авыл халкының бәхетле киләчәк көтеп алдануына, сүз саен ялган сөйләнүгә җаны әрни. Шагыйрь өчен туган ягы газиз анасы кебек үк алыштыргысыз, ул аларга баш иеп рәхмәт укый: *Туган җирем белән туган анам, / Сезнең өчен көенеп утта янам, / Мирас булып сезгә җырым калсын, / Рәхмәт яусын!* [1: 31] («Рәхмәт»). Публицист, тәнкыйтьче М. Әхмәтҗан фикеренчә, Г. Афзал өчен туган ана белән туган җир – синонимнар [2: 169]. Әлеге синонимнар рәтен авторның туган телгә мәхәббәте, татар кешесенә илтифаты белән дә тулыландырып булыр иде. Әдип шигырьләрендә туган телнең Тукай, Җәлил, Такташлар теле булуын ассызыклый: *Җырла, диеп бирде миңа туган җирем / Тукай телен, Такташ телен, Җәлил телен. / Туган илем, бетсә телем – бетә сүзем, / Якты көн дә кирәк түгел, чыксын күзем!* [1: 24]. *Кешелегең, татарлыгың такытокы, / Ана телен онытканның аты корсын. / Пәйгамбәр бул, тугыз*

*телдә китап укы, / Өстәлеңдә иман булып Тукай торсын!* [1: 232]. *Телем барда үргә омтылырмын, / Күз өстендә торган каш кебек. / Телем бетсә, мин дә онтылырмын, / Күл төбенә төшкән таш кебек* [1: 60] («Ана теле»). Язучы, әдәби тәнкыйтьче Г. Гыйльманов Г. Афзалның тел проблемасын культ дәрәҗәсенә күтәрүен билгеләп үтә [8: 40] һәм югарыда каралган шигырь юллары – шуның ачык мисалы. «Онытма» шигырендә «туган як» төшенчәсе «татарлык» төшенчәсе белән тиңләштерелә: *Туган якларыңны онытма! / Татар икәнеңне онытма!* [1: 104]. Татарны зурлый, бу җирнең хуҗасы икәнлегенә (*Бабайлар сөяге – Болгарда, / Килмешәк түгел без бу җирдә. / Ат аунаган җирдә төк калды*), күпме генә юк итәргә теләсәләр дә тамыры тирән булуына (*Урманны кистеләр, төп калды. / Төп астында – тирән тамырлар, / Шул тамырдан безне таныйлар* [1: 105]) төшендерә. Күрәбез: Г. Афзал иҗатында туган җир, туган тел, газиз ана, татар кешесе – бер-берсе белән гаять тыгыз бәйләнештәге бербөтен. Автор аларның һәркайсын бертигез ярата. Ил, милләт язмышы белән бәйле проблемалар аның җанын борчый.

Г. Афзал шигырьләрендә мәхәббәтнең яшәтүче көч булуы раслана: *Шундый вакыт була: киң дөньяда / Бер кеше дә сине сагынмый. / Гомер уза, гүя елга ага, / Күңел йоклый, канат кагынмый / Тузан баскан йөрәк кылларына / Ак канаттай бер кул кагыла – / Гүзәл нурлар чәчеп елларыңа, / Йөрәк балкый, йөрәк кабына. / Син булганга / Гомер бизәкләре мул хыялда, / Тирән уйлар йөзә күк томанда, / Бу басулар, бу болыннар ямьле, / Бу дөньялар ямьле син булганга* [1: 7, 8]. Авторның «Айлы кич», «Мин яратам сине» шигырьләре дә лирик җылылык белән сугарылган. Мәгълүм булганча, татар шигъриятендә табигать белән якынлык, аны зурлау борынгыдан килә. Моның өлгеләрен Г. Тукай, Дәрдемәнд, Һ. Такташ шигырьләрендә үк күрергә мөмкин. Г. Афзал да әлеге традициягә тугрылык саклый. Ул иҗатында табигатьнең гүзәллегенә, сафлыгына соклана, «кеше рухына табигать сурәте аша юл ала» [5: 103]: «Кышкы урман», «Кышкы иртә», «Идел ага», «Сабан тургае», «Көзләр җитә», «Тирәк», «Ялгыз нарат», «Яз», «Моң», «Яңгыр алдыннан» шигырьләре туган як кадеренә төшендерүдә, табигать матурлыгын күрергә өйрәтүдә зур тәрбияви әһәмияткә ия. Табигатьнең гүзәллеген, андагы үзгәрешләрне әдип аерым бер җылылык белән сурәтли, бер шигырендә яңгыраганча, гүя *чәчәкләрдән нәфис төсләр алып*, матур тел белән яза. Аның шигырьләрендә иманнәр күрәзәлек итә; кара кучкылланып, болытлар каш җыера; моңсу уйга калып, офыклар сүрәнләнеп кала; әрәмәләр уйчан төскә керә; күләгәләр йөгерә. Автор табигатьтәге үзгәрешләрне сынландырып, кеше табигатенә охшатып бирә. Бу уңайдан Татарстанның халык шагыйре Р. Фәйзуллин сүзләре игътибарга лаек: «Г. Афзал табигатьне үтә нечкә тоеп, садә һәм халыкчан итеп тасвирлый ала; тасвирлап кына калмый, аны кешеләр күңеленә якынайта яки кешенең үзен табигатькә күзгә күренмәс җепләр белән бәйли, аларның берлеген искәртеп тора» [14: 118]: *Айлы төндә бәсле урман юлы, / Бер*

*карасаң, хәйран калырлык. / Гүя монда сихри әкият тулы, / Җем-җем итеп торган матурлык. / Фирүзәдәй зәңгәр күк фонында / Чыршылар ак бүрек кигәннәр. / Тирән уйга талып ай нурында, / Күрәзәлек итә имәннәр* [1: 10] («Кышкы урман»). *Якты бәхет җылы нур өләшә, / Чәчәк белән чәчәк чеңләшә, / Ботакларын иеп, сер сөйләшә / Каен белән зирек янәшә...* [1: 83]. *Алмагачлар утыра ак тун киеп, / Хәерле көн, диеп... / Ак каеннар оеп тын утыра, / Баскан сихри йокы. / Хаким булып йөри кичләрендә / Пима белән бүрек. / Уҗым йоклый татлы төшләрендә, / Җылы язлар күреп* [1: 88] («Кырлач»).

Кыска шигырьләр остасы буларак, Г. Афзал аларда тормыштагы, кешеләрдәге кимчелекләрне, мантыйксыз гамәлләрне (ришвәтчелек, ялагайлык, икейөзлелек, караклык, оятсызлык, ялган һ. б.), хакыйкатьне үткен теле белән турыдан яра. Түбәндәге тезмәләр – шуның ачык мисаллары: *Хак булса да гәрчә, ят күренә / Ялгышыңны әйтеп бирүче. / Былбыл булып куна әй түреңә / Матур итеп алдый белүче* [1: 115]. *Яңа тормыш төзибез, дип, / үлгәнче чабасы бар... / Халыкны алдап торуның / чиге бар, чамасы бар* [1: 99]. *Гел фикерсез кеше озын сөйли, / Буш икәнен белмәсеннәр өчен* [1: 233]. *Елан тоткан кебек, бик җирәнеп, / Әрем йоткан кебек, сытып йөзне, / Мин сүзлектән сызып ташлар идем / Блат белән Ришвәт дигән сүзне* [1: 233]. *Утырасың җәмгыятьнең җилкәсендә, / Хәйлә җебен чорныйсың да, сүтәсең дә, / Бөгеләсең, сыгыласың, елмаясың, / Матур кулың җәмгыятьнең кесәсендә* [1: 234]. Кешенең холык-психологиясен үтә нечкә тойган әдип түбәндәге шигъри юллары белән икейөзле, ясалма кеше портретын аермачык итеп күз алдына китереп бастыра: *Көлә-көлә сүз уйната, күз уйната. / Яңагында алсу уймак бата-калка, бата-калка. / Йөзендә – нур, күзендә – нур, телендә – бал, / Йөрәгендә йомарланып елан ята* [1: 235].

Г. Афзалның татар мәдәниятен үстерүгә биниһая зур өлеш керткән шәхесләргә: Г. Утыз-Имәни, Г. Кандалый, Дәрдемәнд, М. Акъегетзадә, М. Мутин, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, М. Фәйзи, Ш. Бабич, И. Салахов һ. б. га багышланган шигырьләре иҗатының аерым бер юнәлешен билгели. «Авылдашым Мөхтәр Мутин» шигырендә автор театр артисты, шәхес культы корбаны М. Мутинның фаҗигалы язмышын тулы итеп күз алдына бастыра һәм гаять дөрес нәтиҗә ясый: *Талантлы булу да гөнаһ икән / Социализм дигән бардакта* [1: 102]. Дәһшәтле сугыш елларында дошман алдында тез чүкмәгән каһарман шагыйребез Муса Җәлил Ватанга тугрылыгын җиргә тамган кызыл каны, көчле коралга әверелгән шигъри юллары белән раслый. Милләтебез горурлыгы булган шагыйрьгә Г. Афзал «Җәлилләрең, Такташларың», «Туган илем», «Муса Җәлил һәйкәле» һ. б. шигырьләрен багышлый.

Ватанпәрвәр шагыйрьне татар халкының тарихи үткәне, катлаулы үсеш юллары, ил, милләт язмышында җитди роль уйнаган шәхесләре уйландыра, аларның ачы язмышлары җанын әрнетә. Бу аның «Сөембикә сылу» (легенда), «Болгар бәете», «Болгар төне»,

«Болгарлар», «Алтын бөртек», «Китаплар язмышы», «Сарматлар», «Тарих мең дә...», «Идел башы», «Бату хан», «Гомер кичүләре» җыентыгында урын алган «Төркиләр моңы» циклы, «Болгар ташлары», «Алтын Урда», «Биләр», «Дәште Кыпчак», «Курганнар төш күрә», «Казан күкләрендә ак болыт», «Тарих сабаклары» һ. б. әсәрләрендә аеруча ачык чагылыш таба. Тарихи үткәннәрне актарып, әдип чал тарихыбызны тергезә, бай тарихлы үткәнебезне белергә, бәяләргә һәм беркайчан да онытмаска өнди. Г. Афзал иҗаты гаять күпкырлы. Бу уңайдан шагыйрь М. Мирза сүзләре игътибарга лаек: «Афзал шигърияте – үзе бер хәзинә. Аның гыйбрәтле, ачы язмышы белән үрелеп бар булган үлемсез иҗат! Сабаклары нык, төз, биек, башаклары тук аның иҗатының» [12: 113]. Әдипнең иҗаты да үзе кебек үк ихлас дип өстисе килә.

Г. Афзал шигъриятендә юмор һәм сатира аерым урын алып тора. «Гамил Афзалның сатирасы – үзе зур мәктәп» [12: 110], дигән сүзләрдә хаклык зур. Әдәбият галиме Т. Галиуллин фикеренчә, Г. Афзалның сатирасы – «хаклыкны ялганнан аеруда арадашчы, яшәешнең авырлыкларын җиңүдә ярдәмче, кайгыда юаныч, шатлыкта сердәш, көрәштә киңәшче» [4: 137]. Аның иҗаты белән таныш һәркем әдип сатирасының үткен телен Г. Тукайныкына охшата. М. Юныс аны «Тукайга якынлаша алган шагыйрьләрнең берсе... Габдулла Тукай башлап җибәргән иҗат кыйбласына тугрылыклы татар шагыйре...» дип атый [18]. Т. Галиуллин, С. Хәким сүзләрендә дә шуңа охшаш фикерләр яңгырый. Әдәбият галиме Д. Заһидуллина Г. Афзалның «1960–1980 еллар поэзиясендә моңа кадәр бер шагыйрь иҗатында да күренмәгән кеше концепциясе пәйда булуын» [10: 4] билгеләп үтә. Бу уңайдан галим әдипнең юмористик-сатирик шигырьләренә туктала; аның «кыю, үз фикерле, киң карашлы шагыйрь булуын» ассызыклый. Аларда шагыйрьнең «эзоп теле» алымы ярдәмендә тормыштагы, шулай ук кешеләр холкына хас кимчелекләрне фаш итүен мисал-дәлилләр белән раслый. «Г. Афзал поэзиясе, аның юморы һәм образлар системасы – безнең әдәбиятыбызда уникаль күренеш, – дип яза Ф. Садриев. – Аның сатира-юморы яктылык белән сугарылган. Яхшы күңелле кешеләр генә шулай якты, кояшлы итеп көлә белә» [13: 139, 140]. Аның максаты – «гаеплене үтерү түгел, бәлки көләкөлә тәрбияләү. Кытыклый-кытыклый дөрес юлга кертә ул адәм баласын» [3: 151]. Көлү – «халыкның рухи дөньясы, җәмгыятьнең үсеше белән бәйле күренеш» [17: 296] буларак, шагыйрь үзенең әсәрләрендә иҗтимагый тормыштагы яисә кеше холкындагы һәртөрле тискәрелекне, затсызлыкны я турыдан-туры, яисә «елмаеп, ирониягә төреп хуплау» [7: 235] аша фаш итә. Шагыйрьнең бериш сатирик-юмористик шигырьләрендә («Гадел эшкә сәбәп», «Кыяр-кыймас», «Мыек борам», «Елмаям уйчан гына...», «Бигрәк юаш басып йөрдем җиргә», «Сак кеше»), галимнәр билгеләп үткәнчә, куркак кеше психологиясе яктыртыла. Беришеләрендә исә, әйтик, «Сәләхетдин бабай сүзләре», «Механик кемне сүгә», «Тотып җибәр, апаем...», «Җыелыштан соң

уйлану», «Их, бар иде түрә чаклар...», «Карт егет хәле», «Ревизор көткәндә», «Эшеннән азат ителгән бюрократ зары», «Шәрифулла күршем белән», «Кайгырмасов хикәясе» һ. б. шигырьләрендәге персонажлар яман гадәтләренең коллары буларак гәүдәләнәләр. Шагыйрь үзенең «көлке типларын монологлары аша ачып бирә» [15: 144], ягъни бу персонажлар үзләрен, сатирик әсәрләргә хас булганча, үз телләре белән фаш итәләр. Бу аның «Минем сакал», «Сайладым, их, сайладым», «Шәрифулла күршем белән», «Сәлахетдин бабай сүзләре», «Сабитның Советка сайланасы килә» шигырьләрендә аеруча ачык чагылыш таба. Кайбер персонажларының сөйләм теле аша эчке бушлыклары, ихтыяри көчсезлекләре, тәрбиясезлекләре фаш ителә: «Аракыга каршы», «Механик кемне сүгә», «Фикус-микус гөлләр тездем...» һ. б. Тынгысыз һәм күзәтүчән шагыйрьнең үткен күзеннән бер генә кимчелек тә качып кала алмый. Кайвакыт Г. Афзалның көлүе, югарыда искәртелгәнчә, җылы, кешелекле, аның тискәре персонажлары нәфрәт уятмый, ул аларны нәфрәт чәчми генә оялта белә. Караклыкта тотылган динле, тәрбияле әби («Тәвәккәл әби»), ирдән иргә йөрүче Әсмабикә («Әсмабикә җаным, ахирәт»), дыңгычлап бодай тутырылган эчке киеменең сәдәфе чыдамыйча өзелеп харап булган Бибизәйнәп («Гөнаһ шомлыгы»), өйдән өйгә сүз ташып, гайбәт таратып йөри торгач, салкын тидереп урын өстенә егылган, һәм үзе хурлаган күршеләре хәлен белергә кергәч, ояты уянган Мәүҗидәттәй («Мәүҗидәттәй») – шундыйлардан. «Өф-өф итеп» шигырендә балаларга дөрес тәрбия бирмәүнең, ягъни артык иркәләүнең аяныч нәтиҗәләре ачык күрсәтелә. Кайбер тискәре күренешләрне, аеруча мещанлык чире белән «авыручы» әрәмтамакларны әдип әрем теле белән камчылый. Ул җиңел генә югарыга үрмәләргә тырышкан надан, ялагай, булдыксыз куштаннарны *(Бал да бирми, май да бирми төклетура, / Сәясәткә җайлашырга план кора. / Җитәкчеләр ни әйтсә дә – ура-ура! / Гомер буе шикләнеп һәм куркып тора* [1: 219]), үзенең җылы һәм түшемле урыны турында гына кайгырткан, җаваплылыктан качарга тырышкан ваемсыз җитәкчеләрне («Урынбасар булу яхшырак»), тәкәббер, гаделсез, хыянәтчел түрәләрне («Тәнкыйть сөймәүче Күркә»), җинаятьчел күренешләргә күз йомган туң йөрәкләрне, күз буяучылык, бюрократизм кебек заман чирләрен сатира утында яндыра. «Кешенең күңелен, җанын кечерәйтүче мещан психологиясен тамырыннан йолкып алырга омтылу, мондый куркыныч социаль эпидемиягә каршы ут ачу кебек сыйфатлар Гамил Афзал сатирасын көрәшнең иң алгы сафына куя» [11: 164]. Шигырьнең исемендә үк юмор ярылып яткан «Кара песинең этлеге» шигырендә юлларын кисүче кара мәчегә мөнәсәбәтле җаваплы вазифа башкаручы кешеләрнең кыңгыр эшләре фаш ителә, гаепне үзләрендә күрмичә, юлларын кисеп үтүче мәчене гаепләүләре көлке уята. Биредә «гаебең булса, куркуың һәм шигең артыр» дигән фикер уздырыла. «Тантаналы утырыш» шигырендә хисап өчен генә уздырылган утырышка мөнәсәбәтле автор: *Тик утырып акча алган кеше, / Зур эш кырып, трибунадан*

*төште. / Чәчерәп чыкты нәфис сүз остасы, / Күпме чәйнәсә дә – сүз боткасы. / Сменадан чыккач арып-талып, / Нәфис сүзне тыңламый шул халык* [1: 202], дигән нәтиҗә ясый. «Шәләй Вәләйевич карьерасы» шигырендә эшкә шәләй-вәләй карауның ахыры бик кызганыч бетүенә төшендерә. «Шайтан» шигырендә кешенең күңелендәге ике төрле «мин»е арасындагы диалог-көрәшне үтемле күрсәтә. «Бер төркем иптәшләр» шигырендә урман җәнлекләре – Аю, Бүре, Төлке һәм Куян мисалында «эзоп теле» аркылы кешеләр холкына хас кешелексез гамәлләр фаш ителә: власть – башында бөек Арыслан утырган кансыз Аю, явыз Бүре һәм хәйләкәр Төлке кулында. Агымдагы оператив эшләрдән соң, кадрлар мәсьәләсен хәл итәләр: штатны кыскартырга кирәк икән, Арыслан алдында җавап тотасылары бар. Беркайчан да урлашмаган, уңга-сулга тайпылмаган, туры юлдан гына чапкан тыйнак, әмма гаять куркак Куянны, «тәртип бозган» дигән нахак бәла ягып, юк итәргә булалар. Бу иптәшләргә «Кемнең кулында – шуның авызында» мәкале бик туры килеп тора; биредә автор ялган, явызлык, икейөзлелек, җинаятьчелеккә юл ачкан системага, гади халык аңына курку хисе сеңдергән идеологиягә нәфрәтен белдерә. «Уйлап табучы Куян» мәсәлендә дә җайланманы уйлап табучы зат зирәк Куян булса да, үзләштерүчеләр – баш инженер Төлке белән җитәкче Бүре. «Куян иптәш, синең башта белем сирәк», – дип үзләрен автордаш итеп билгелиләр. *Пөхтә итеп шул сызымны сыздырдылар, / Икәүләшеп елмаешып кул куйдылар; / Соавторлар бүләк алды, дача салды, / Куянга бер сукыр тиен тоттырдылар* [1: 149]. Әлеге әсәрдә авторның нинди дөреслекне җиткерергә теләгәне ачык аңлашыла. Бер хакыйкатьне аңлау мөһим: кешеләрнең кылган гамәлләре – үзләре яшәгән мохитнең, җәмгыятьнең йөзе, илдә хөкем сөргән тәртипләрнең, шулар тудырган рухилык дәрәҗәсенең ачык чагылышы. Г. Афзал да шушы дөреслекне җиткерергә омтыла.

Югарыда күренгәнчә, Г. Афзал шигъриятенең көче һәрнәрсәдән матурлык эзләү, аны табу һәм бәяләүдән гыйбарәт. Шагыйрьнең кешене ярату белән сугарылган, аның эчке дөньясын ачарга, дөньяга карашын ачыкларга тырышкан, тормышка, туган илгә, табигатькә мәхәббәт хисе, тәрбияви көче, фәлсәфи тирәнлеге белән аерылып торган, «зирәк интеллектка ия» [5: 118] тормышчан һәм халыкчан поэзиясе, матурлык, гаделлек хакына һәртөрле караңгылыкны, ямьсезлекне үтемле фаш итүче сатирасы бүгенге көндә дә актуаль булып кала. Г. Афзалның «намуслылыгы, тыйнаклыгы, ихласлыгы белән матур» [3: 150] шигърияте – үзе бер зур тәрбия мәктәбе.

**Әдәбият**

1. *Афзал Г.Г.* Рәхмәт!: лирика, юмор, сатира / төз.-мөх-р Ленар Шәех. Казан: Рухият, 2009. 288 б.

2. *Әхмәтҗан М.* Шигърият аша тәрбия // Казан утлары. 1994. № 5. Б. 166–173.

3. *Баттал С., Яхин А., Баттал Ф., Зөлфәт.* Олы шагыйребез бар (Г. Афзалның тууына 70 яшь тулу уңаеннан) // Казан утлары. 1991. № 5. Б. 148–151.

4. *Галиуллин Т.Н.* Шигърият баскычлары: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Мәгариф, 2002. 231 б.

5. Гамил Афзал: мәкаләләр, истәлекләр, шигырьләр, хатлар, әңгәмәләр. Казан: Рухият, 2016. 327 б.

6. *Гаташ Р.* Гамь һәм моң илчесе // Казан утлары. 2001. № 5. Б. 9–11.

7. *Гилаева И.* Гамил Афзал // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда / [төз. Р.Ф. Рахмани]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. 6 т.: 1960–1980 еллар / [фәнни мөх-р: Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов]. 2018. Б. 291–308.

8. *Гыйльманов Г.* Шагыйрьнең биеклеге: образлар дөньясына күзәтү // Г. Афзал. Гомер кичүләре: Шигырьләр / төз.-мөх-р Г. Гыйльманов. Казан: Рухият, 2000. Б. 5–42.

9. *Дәүләтов Зөфәр.* Соңгы көннәр хатирәсе // Казан утлары. 2005. № 7. Б. 170–171.

10. *Заһидуллина Д.Ф.* Татар әдәбиятына хас милли үзенчәлекләр: Икенче эчтәлек тудыру // Tatarica: Казан КФУ. 2013. № 1. Б. 115–126.

11. *Кәшфи Л.* Гамил Афзал көлүе // Казан утлары. 1990. № 5. Б. 162–165.

12. *Мирза Мөхәммәт.* Гомерләр кичкәндә // Казан утлары. 2016. № 5. Б. 110–118.

13. *Садриев Ф.* Йөрәге халык күкрәгендә // Мәйдан. 2004. № 2. Б. 139–140.

14. *Фәйзуллин Р.А.* Халыкчан шагыйрь // Казан утлары. 1971. № 5. Б. 114–122.

15. *Хисамов Н.* Матурлык хакына // Казан утлары. 1969. № 6. Б. 143–149.

16. *Шәех Л.* Пәйгамбәргә тиң шагыйрь // Ватаным Татарстан. 2005. 26 авг.

17. *Юзиев Н.* Гамил Афзал // Татар әдәбияты тарихы: Алты томда: 6 т.: 60–90 еллар әдәбияты. Казан: Раннур, 2001. Б. 283–299.

18. *Юныс Миргазиян.* Үзе китте, җыры калды // Татарстан яшьләре. 2003. 25 сент.

***Каюмова Гөлия Илдус кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА М. Хәсәнов исемендәге Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты өлкән фәнни хезмәткәре*

***Каюмова Гульия Ильдусовна,***
*кандидат филологических наук, старший научный сотрудник Института татарской энциклопедии и регионоведения имени М. Хасанова АН РТ*

*guliya.kayumova@yandex.ru*